МИНИСТЕРСТВО
ТРУДА, ЗАНЯТОСТИ И
СОЦИАЛЬНОЙ ЗАЩИТЫ
РЕСПУБЛИКИ
ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ХЕЗМӘТ, ХАЛЫКНЫ ЭШ
БЕЛӘН ТӘЭМИН ИТҮ ҺӘМ
СОЦИАЛЬ ЯКЛАУ
МИНИСТРЛЫГЫ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ — КАРАР

19.11.2019 Казан ш. № 13

Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгында 2019 елның 9 декабрендә 5977 номеры белән теркәлде

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының «2019 елга Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан эш бирүчеләргә инвалидларны эшкә урнаштыру өчен квота һәм социаль яклауга аеруча мохтаҗ инвалидларны һәм гражданнарны эшкә урнаштыру өчен резервланырга тиешле эш урыннары санын билгеләү турында» 2018 елның 25 сентябрендәге 9 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан оешмаларда инвалидларны эшкә урнаштыру өчен эш урыннарына квоталар билгеләү тәртибе турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2007 елның 4 маендагы 170 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан оешмаларда инвалидларны эшкә урнаштыру өчен эш урыннарына квоталар билгеләү тәртибе турындагы нигезләмә нигезендә Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының «2019 елга Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан эш бирүчеләргә инвалидларны эшкә урнаштыру өчен квота һәм социаль яклауга аеруча мохтаҗ инвалидларны һәм гражданнарны эшкә урнаштыру өчен резервланырга тиешле эш урыннары санын билгеләү турында» 2018 елның 25 сентябрендәге 9 номерлы карарына (Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының 2019 елның 27 маендагы 11 номерлы карары нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1 пунктта « 983» саннарын «979» саннарына алмаштырырга;

1 нче кушымтада:

«Татарстан Республикасы җәмгысе» юлында «16086», «583», «361» саннарын тиешенчә «16029», «580», «360» саннарына алмаштырырга;

238 пунктны гамәлдән чыккан дип танырга;

2 нче кушымтада:

«Татарстан Республикасы җәмгысе» юлында «59197», «7685», «13,0», «1058», «622» саннарын тиешенчә «58932», «7692», «13,1», «1054», «619» саннарына алмаштырырга;

17 пунктта:

2 нче графада «СВЯЗЬ-безопасность» федераль дәүләт унитар предприятиесе филиалы – Татарстан Республикасы буенча ведомство саклау идарәсе» сүзләрен «Росгвардиянең «Охрана» федераль дәүләт унитар предприятиесе (филиал) Элемтә объектларын саклау үзәге Көнбатыш округы идарәсенең Татарстан Республикасы бүлеге» сүзләренә алмаштырырга;

3, 4, 5, 7 һәм 9 графаларда «256», «13», «5,1», «0,4», «1,6» саннарын тиешенчә «165», «27», «16,4», «0,6», «2,4» саннарына алмаштырырга;

149 пунктны гамәлдән чыккан дип танырга.

2. «Мәскәү районы халыкның мәшгульлек үзәге» дәүләт казна учреждениесе, «Түбән Кама шәһәре халыкның мәшгульлек үзәге» дәүләт казна учреждениесе директорларына, Кама Тамагы районы буенча Тәтеш районы халыкның мәшгульлек үзәге филиалы мөдиренә әлеге карар рәсми басылып чыккан көннән башлап эш көннәрендә исәпләнгән 5 көнлек срокта әлеге карар кабул итүгә бәйле рәвештә 2019 елга инвалидларны эшкә урнаштыру өчен үзләренә билгеләнгән квота саны һәм (яки) инвалидларны һәм социаль яклауга аеруча мохтаҗ гражданнарны эшкә урнаштыру өчен резервка куела торган эш урыннары саны үзгәрә торган эш бирүчеләргә язмача рәвештә хәбәр итәргә.

3. Әлеге карар үтәлешен тикшереп тору буенча министр урынбасары К.А.Таҗетдинованы җаваплы итеп билгеләргә.

Министр Э.Ә.Зарипова